Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

9 август 2019 ел № 115

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2009 елның 7 апрелендәге «Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын һәм терлекләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында" 108 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының «Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын һәм терлекләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 7 апрелендәге 108 номерлы карарына (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
Карарның 1 нче кушымтасының 2 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«йорт хайваннары - хуҗасы-физик зат карамагында булган хайваннар (асралуга тыелган хайваннар исемлегенә кертелгән хайваннардан тыш), аның вакытлыча яки даими күзәтүе астында булган һәм аларны тоту урыны зоопарклар, зоосадлар, цирклар, зоотеатрлар булмаган хайваннар;».
2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14 һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы Рәисе И.Х.Сәгдиев